

8 гасыр урталарыннан безнен коннәргә кадәр татар хатын-кызларынын бизәнv әйберләре сакланган. Нигездә алар алтын-комештән, бакырдан, бронзадан ясалган.
- Татар халыкынын борынгы милли киеме - чын мәгънәсендә халыкнын кvнел козгесе. «Татарда бар кием, - ди vзенен хезмәтендә мәгърифәтче Каюм Насыйри, - кvлмәк, штан, камзул, казаки, жилән, чапан, чикмән, кыска тун, кәвеш, башмак, бvрек, такыя, кәләпvш», - һәм vз мәкаләсенен азагында урта хәлле бер татар «нечкәбилен» нәфис гvзәл киемнәргә киендереп карау могжизасын башкара. Нәкъ менә хатын-кыз татар милли киемендә торле сәнгать казанышлары уйнап тора да инде: монда комеш-челтәр хәситәләр, беләзек-алкалар, муенсалар, укалы калфак һәм каюлы итек, - дип татар әдәбияты дәресләрендә сойләп китә Сания Спартак кызы Саляева, Рузаевка районы Татар Пешлә авылы укытучысы. Аннары Пешлә халкы элек һәм бvген ничегрәк татар милли киемнәрен тормышларында куллануга кvчә. Мона дәлилләр мәктәп музеенда һәм ясалган презентацияләрендә кvренә. Әйтеп китәргә кирәк, бу мәктәпнен тегv бvлмәсендә бvген укучылар татар милли бизәкләр белән матурланган, бәби итәкле алъяпкычын тегеп кияләр.
Ә беләзекләргә килгәндә, алар ике торле була: беренчесе тоташ кисәктән ясалган һәм чылбыр рәвешендәге ике - оч шар ватыгы кисәкчәләреннән тоташтырып эшләнгән беләзекләр; икенчесе - торле чылбыр формасындагы бизәкләрдән ясалган. Комеш һәм алтыннан эшләнгән бизәнv әйберләре аеруча кызыксыну уята. Алар хатын-кызларнын милли киемнәрен тулыландырып торганнар.
Әбиләребездән сораштырып чулпыны, торле яшьтәге татар хатын-кызлары яратып куллана торган бизәнv әйберен, беләбез. Аны яшvсмер чактан тага башлаганнар. Гади генә юл белән кара бауга бәйләнгән яки тоташтырып тегелгән бер-ике, кайчагында аннан да кvбрәк эре комеш акчалардан торган чулпыларны, билдән астарак тошеп торырлык итеп чәч толымнарына бәйли торган булганнар. Тагы чәч тәнкәсе яисә тезмә - кызларнын чәчләренә тага торган бизәнv әйбере булган. Ул 2-3 см кинлектә, 80 см озынлыкта тар гына ике киндер тукыма кисәгеннән, ефәк тасмадан яки укалы тасмадан тора. Шундый бизәнv әйберләрен алмаштырган заколкалар, бантлар һәм башка чәчне бизәv очен матурлаткычларны бvген vзебез яратып кулланабыз, дип сvзен йомгаклый укытучы.
- Алка - барлык татар хатын - кызлары арасында ин кин таралган бизәнv әйбере. Мордовия татар хатын-кызларын алкасыз, беләзек-йозексез итеп кvз алдына да китереп булмый. Һәркемдә, хәтта ярлырак гаиләләрдә дә комеш алка, беләзек-йозекләр

кыз-кыркын, ханым-туташларнын кvнелен жылыта торган байлыкка әверелгән. Бу шулай борын-борыннан ук килеп безнен коннәргә житкән гореф-гадәт. Казылмаларнын кvбесендә бизәнv әйберләре комештән коелганнарын тапканнар. Сирәк кенә алтын алка, балдаклар да булган. Алтын йогертелгән комеш бизәнv әйберләре дә кин таралган булган, ә бакыр, жиз, аккургаш, мельхиор, никель кушылмаларыннан бизәнv әйберләре эшләv ул чакта кулланылмаган, - ди Туган якнын тарихы, мәдәнияты, әдәбияты темасын ачыклаган темасында Ләмберә районы Пензятка авылы мәктәбе укытучысы Рауза Мокаддәс кызы Юмаева. - Ко¬меш алка, йозек, беләзек, муенсалар милли киемгә ямь, матурлык, миллилек ости торган остәмә, анын бер олеше итеп кабул ителгән. Кием фасоннары vзгәрv белән бизәнv әйберләре конкvрештән тошеп калган. Аларга музей жыелмаларында гына саклану язмышы язган. Хәер, әбиләр сандыгын актарып караган яна буыннар гаилә ядкаре булып ин топтә яткан кадерле, нәфис бизәнv әйберләренен матурлыгына еллар vткәч тә сокланадыр.

Йозекләр урта гасырларда ук татарлар очен кыйммәтле һәм кирәкле бизәнv әйберләренә әйләнә. Йозек кию мәжбvри саналган, чонки хатын-кызларга кулларын кvрсәтеп йорv хәрәм дип исәпләнгән. Йозек кимичә ризык әзерләргә керешv макталмаган. Ә кунакка барганда туташлар һәм ханымнар һәр бармагына, кайчакларда хәтта икешәр-очәр йозек кия торган булганнар. Бvгенге модабыз шуны кабатлый. Мондый йола хакында кvп кенә тарихчылар язып калдырган, бу хакта К. Фукс та искәртә. Һәм монын анлатмасы да кызыклы. Кул бармакларынын беренче буынына, имештер, кvз тиярга момкин, шуна кvрә дә ана йозек кию яхшырак икән. Урта гасырларда яшәvчеләрнен йозеккә монәсәбәтен Гомәр Хайям дә искәртә: «Йозектән гайре һәр торле бизәнv әйберен кешеләр киргә дә, кимәскә дә момкин. Ә йозексез булу килешми».

Торле басма һәм интернет чыганакларда кашлы йозекләр аеруча ихтирам ителгән, дип язалар: «...кыйммәтле ташлар, минералларда тылсым коче булуына ышану зур булган. Затлы ташлар куркакка - кыюлык, тәвәккәллек, әдәпсезгә - тыйнаклык, ялкауга эш дәрте ости, чибәрләрне кvз тиюдән саклый дип ышанганнар. Аларда дәвалау коче булуына шикләнмәгәннәр. Зобәржәт тамак бакасын, бизгәкне куа, кызыл якут кан басымын һәм тән температурасын тошерә, йорәк тибешен тәртипкә китерә һәм буыннар авыруы, ревматизм вакытында файдалы. Энже - чисталык символы. Мәржән (коралл) аппетитны яхшырта һәм бизләр ялкынсынудан саклый. Гәрәбәнен һәм кайбер башка ташларнын дәвалау vзенчәлекләрен хәзер инде фән дә раслый. Татар хатыннары арасында фирvзә (фирvз - фарсычадан жинv дигән мәгънәгә ия) һәм ахак (хакыйкать - чынлык) аеруча зур мәхәббәт казанган. Гадәттә, зур ахак тирәли кечкенәрәк фирvзәләр тезелгән бизәнv әйберләренә ихтыяж зур булган. Йозек кашында ташларнын шул рәвешчә урнашуы явыз кочләрдән һәм кvз тиюдән саклый дигән ышаныч тамыр жәйгән. Йозек һәм бизәнv әйберендәге кашларны «кvз» дип атау гадәткә кергән. «Кvз» - кvз тиюдән саклаучы коч булуына ышану хәзер дә яши.

Йозекләрнен тvгәрәге, дvрт, алты, сигез кырлылары булган. Шомалары белән беррәттән, чvкеп һәм чокып сурәт тошергәннәре, гарәп сvзләре язылганнары бар. Хатын-кызлар кия торганнарына кайчакта йозек иясенен исеме һәм теләкләр дә сырланган. Геометрик, дулкынсыман бизәкләр, рун язуы, тамгалар, хайван, кош рәсемнәре, аждаһа, хыялый сурәтләр дә еш очрый. Балдак-йозекләрнен халык әкиятләрендә, риваять, поэмаларда еш кына ин авыр чакта кешеләргә ярдәмгә килvе сурәтләнә. Балдакларны ирләр дә кигән. Алар очен ул бизәнv әйбере тvгел, ә бәлки тормыш очен кирәкле – таныклык-имза

ролен vтәvче моһер сыйфатында файдаланылган. Нинди дә булса вазифа башкаручы һәр ир-ат ун кулынын чәнчә-чәнти (мизинец) бармагында «йозек-моһер» йорткән. Ханнар, әмирләр очен йозек хакимлек символы булса, кайчак йозек иясенен нинди һонәр иясе булуын да kvрсәткән. Кашсыз, «рәжәби» балдакларны комештән осталар рәжәб аенда койганнар, изге булып исәпләнә».

Нәтижә шундыйрак. Зәркән әйберләр берничә торле функция башкарган: kvз тиюдән саклау, vзеннекеме, тvгелме икәнлеген аеру, йозек иясенен биләгән вазифасын, бай яки ярлы булуын kvрсәтv чарасы булып торган. Бу олкәдә мәгълvмат аз, йозекләрнен кайсылары татарлар тарафыннан эшләнгәнен, kvпмесе читтән китертелгәнен ачыклау читен. Шунысы бәхәссез, татарларда йозек кию кин таралган. Археология материаллары шуны раслый.

Н.Хәлил